ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2023 г.Лениногорск № 171

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмә турында» 2019 елның 23 октябрендәге 208 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының үтәлеш үзенчәлекләрен билгеләү турында»2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән һәм Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмә турында» 2019 елның 23 октябрендәге 208 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

а) 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр 24 статьясының 3 пункты, 27 статьясының 3 пункты (бюджет турында карар нигезендә муниципаль гарантияләр бирү өлешендә) гамәлдә булуын туктатып торырга.

б) 38 статьяда 1-5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Шәһәр Советына чираттагы финанс елына бюджет турында карар проекты кертелгән көннән алып бер эш көне эчендә Совет рәисе аны контроль-хисап палатасына һәм Лениногорск шәһәре прокуратурасына экспертиза уздыру өчен җибәрә.

Контроль-хисап палатасы биш эш көне дәвамында, ачыкланган очракта, әлеге проектның кимчелекләрен күрсәтеп, бюджет турында карар проекты турында бәяләмә әзерли.

Лениногорск шәһәре прокуратурасы ун көн дәвамында, ачыкланган очракта, әлеге проектның кимчелекләрен күрсәтеп, бюджет турындагы карар проектына бәяләмә әзерли.

Лениногорск шәһәре Контроль-хисап палатасы һәм шәһәр прокуратурасының бәяләмәсе шәһәр бюджеты турындагы карар проектына төзәтмәләр әзерләгәндә исәпкә алына.

2. Шәһәр Советы рәисе Лениногорск шәһәре контроль-хисап палатасы һәм прокуратурасы бәяләмәсе нигезендә шәһәр Советының район бюджеты турында йә аны эшләп бетерү өчен башкарма комитетка кайтару турында карар кабул итә.

Шәһәр бюджеты турында барлык кирәкле документлар һәм материаллар белән карар проекты Башкарма комитет тарафыннан шәһәр Советына эшләп бетерүгә керешкәннән соң биш эш көне эчендә тапшырылырга тиеш.

Шәһәр Советының даими комиссиясе тарафыннан муниципаль берәмлек бюджеты проекты карала, проектның төп параметрларын хуплап, муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар проектын массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм алга таба гавами тыңлаулар үткәрү максатларында Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру өчен Совет аппаратына җибәрә.

3. Шәһәр Советы шәһәр бюджеты турындагы карар проектын бер укылышта карый.

Проектның гавами тыңлаулар процедурасын уздырганнан соң шәһәр бюджеты турында карар бер укылышта шәһәр Советы тарафыннан карала һәм тәмам кабул ителә.

4. Шәһәр Советы тарафыннан кабул ителгән чираттагы финанс елына бюджет турындагы карар 20 декабрьдән дә соңга калмыйча имза салу һәм бастырып чыгару өчен Совет Рәисенә җибәрелә.

5. Шәһәр Советының район бюджеты турындагы карары чираттагы финанс елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г.Хөсәенов